СОВЕТ СТОЛБИЩЕНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
422624 с.Столбище,
ул. Советская, д.103
тел: 4-12-91

ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СТОЛБИЩЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
422624 Столбище авылы,
Совет урамы, 103 нчы йорт,
тел: 4-12-91

**2022 елның «25» феврале** **3/3 номер**

**КАРАР**

**«Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Столбище авыл җирлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен раслау турында» 2014 елның 22 маендагы 10/1 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 33 статьясы, «Россия Федерациясе җирле үзидарәсен оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Столбище авыл җирлеге Уставы, 2022елның 19 февралендәге гавами тыңлаулар беркетмәсе нигезендә Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Столбище авыл җирлеге Советы карар чыгарды**:**

1. «Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Столбище авыл җирлеге советының 2014 елның 22 маендагы 10/1 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Столбище авыл җирлеге җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен раслау (үзгәрешләр кертү турында) турында» 2014 елның 22 маендагы 10/1 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Столбище авыл җирлеге җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләренә» түбәндәге үзгәрешләрне кертергә::

-«Шәхси торак төзелеше», «шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен», «блоклы төзелеш өчен» рөхсәт ителгән җир кишәрлекләренең минималь күләмен -1000 кв. м.дип билгеләү.

- «Шәхси торак төзелеше», «шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен», «блоклы төзелеш өчен» рөхсәт ителгән җир кишәрлекләренең максималь күләмен -2500 кв. м. дип билгеләү.

Шәһәр төзелеше регламенты тарафыннан билгеләнгән җир кишәрлекләренең чик (минималь) күләмнәре түбәндәге очракларда кулланылмый:

- җир кишәрлеге хосусый милектәге җир кишәрлеген һәм дәүләт милкендәге яисә муниципаль милектәге җир һәм (яисә) җир кишәрлекләрен яңадан бүлү юлы белән һәм мәйданы җир кишәрлекләренең иң чик (минималь) күләменә туры килә торган җир кишәрлеген җирлектә формалаштыру мөмкинлеге булмау юлы белән төзелгәндә;

- җир кишәрлеге ике һәм аннан да күбрәк җир кишәрлекләрен берләштерү юлы белән төзелгәндә;

- гамәлдәге күчемсез милек объекты астында төзелә торган җир кишәрлеге барлыкка килү һәм мәйданы җир кишәрлекләренең иң чик (минималь) күләменә туры килә торган җир кишәрлеген төзү мөмкинлеге булмаганда.

2. Әлеге карарны “Кама ягы”(«Камская новь») район газетасында, Интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб–адресы буенча һәм интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Порталында урнаштырылган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында-http://laishevo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан (игълан ителгән) көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

**Татарстан Республикасы**
**Лаеш муниципаль районы**
**Столбище авыл җирлеге**
**башлыгы вазыйфаларын башкаручы** **В.В. Михеев**